ARAŞTIRMA MAKALESI • RESEARCH ARTICLE • НАУЧНО-ИССЛЕДОВАТЕЛЬСКАЯ СТАТЬЯ

*İdil-Ural Araştırmaları Dergisi,* 2020; 2 (2): 285-297

# ХИЛЬМИЯ АВЫЛЫ ТАРИХЫНА ҺӘМ ФОЛЬКЛОРЫНА МАТЕРИАЛЛАР

АЛЬФИНА СИБГАТУЛЛИНА*

## HİLMİYE KÖYÜ TARİHİNE VE FOLKLORUNA DAİR MATERYALLER

**Öz:** Türkiye'de Kazan Tatar köyleri çok değildir. Karadeniz'in Samsun ili Havza ilçesinde bulunan Hilmiye köyü de küçük fakat dikkate şayan bir yerleşim yeridir. Çünkü Kazan Tatar muhacirleri genel olarak Osmanlı topraklarında denize yakın yerlere pek yerleştirilmemişlerdir. Hilmiye köyünün tarihi üzerine bazı resmî kayıtları 'Arşiv Belgelerinde Kazan' kitabından bulmak mümkündür. Fakat en önemli tarihî hatıratlar Hilmiye köyü sakinlerinin hafızalarında saklanmaktadır. Bu anıları ve köy halkı arasında hâlâ yaşamakta olan Tatar cırlarını, türkülerini toplamak işinde Ahmet Şahin Bey'in ve Bakiye Duran Hanım'ın emekleri vardır. Biz Hilmiye köyünü 2019 yılında ziyaret ettik ve belgeleri, türküleri bizzat Ahmet Bey'in kendisinden ve yakın akrabalarından dinleyebildik. Bu makalede Bakiye Duran Hanım'ın basılı kitabından da faydalanarak, Hilmiye köyü hakkında mevcut belgeleri Tatar okurlara sunmak istiyoruz.

Tatarlar, Havza'ya 1899-1901 yıllarında eski Ufa eyaletinin Sterlitamak ilçesinin (şimdiki Başkurdistan Cumhuriyeti'nin Aurgazı rayonu) Kurmanay, Ismagil, Tolbazı, Sultanmurat köylerinden gelmişler, sonra onlara Kazan'dan gelen muhacirler de eklenmiş. Batum üzerinden Rize kentine gelen muhacirlere yerleşim yeri olarak Çarşamba civarı gösterilmiş fakat orası bataklık yer olduğu için onlar sıtma hastalığına yakalanmışlar ve başka bir yer talep etmek zorunda kalmışlar. Bundan sonra muhacirlere Malatya ve Diyarbakır illerinde araziler verilmiş ancak onlar yerleşim için bu yerleri de uygun bulmamışlar ve anavatanlarına dönmeye karar vermişler. En sonunda şanslarını, o zamanlar Amasya vilayetine bağlı olan Havza topraklarında denemeye karar vermişler ve orada kalmışlar. Tatarlar uzun süre yabancı topraklara alışamamışlar; vatan özlemi, hayat sıkıntısı onların folklorlarına da yansımıştır.

**Anahtar Kelimeler:** Kazan Tatarları, muhaceret, Karadeniz, Hilmiye köyü, Tatar folkloru.

## MATERIALS ON THE HISTORY AND FOLKLORE OF HILMIYE VILLAGE

**Abstract:** There are not so many Kazan Tatars villages in Turkey. Hilmiye village, located in the district of Havza in Samsun province of the Black Sea, is a small but remarkable settlement. One of the reasons for that is Kazan Tatar emigrants usually did not settle in places close to the sea in Ottoman lands. It is possible to find some official records on the history of Hilmiye village if one takes a look into "Kazan in Archive Documents" book. However, the most important memories are kept in stories told

* Prof. Dr., Rusya Bilimler Akademisi Şarkiyat Entitüsü, alfina2003@yandex.ru, ORCID: 0000-0001-5755-8687

(*Yazının Geliş Tarihi/Received Date:* 14.09.2020, *Yazının Kabul Tarihi/Acceptance Date:* 14.11.2020)
Doi: 10.47089/iuad.794839

by the residents of Hilmiye village. Ahmet Şahin and Bakiye Duran undertook a project of collecting these memories and recording Tatar folk songs that still live among the villagers. We visited Hilmiye village in 2019 and had a chance to listen to folk songs and talk to Ahmet Bey and his close relatives. In this article, we want to present to Tatar readers some fact from the history of Hilmiye village by going through Bakiye Duran's book.
Tatars came to Havza in 1899-1901, relocating from the villages of Kurmanay, Ismagil, Tolbazı, Sultanmurat of the Sterlitamak district (now Aurgazı region of the Republic of Bashkortostan, Russia); later a wave of immigrants from Kazan joined them. The Turkish state located immigrants who came to Rize via Batumi around Çarşamba; but because the area was a swamp, the settlers got malaria and had to request another place. After that, the immigrants were given lands in the provinces of Malatya and Diyarbakır; but not having found a suitable place for settlement, they decided to return to their homeland. Finally, the Tatars found their luck in the Havza lands, which back then were part of Amasya province. Yet getting used to foreign lands took them a long time, and this longing for homeland and the existing life troubles found their reflection in Tatar folklore.

**Keywords:** Kazan Tatars, immigration, Black Sea, Hilmiye village, Tatar folklore.

***“Чәчәк идек илләрдә, чәчелдек чит җирләргә...”***
*Татар халык җыры*

## Кереш

Дөнья буйлап сибелгән Казан татарларының Төркия туфракларында бергәләп тормыш корган авыллары әлегә сан ягыннан барланып бетмәгән, тарихлары һәм фольклоры да фәнни яктан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу язмада шундый аз билгеле булган бер авыл турында сүз барачак, мәкаләнең исә, төрекчә яки урысча түгел, махсус рәвештә татар телендә язылуының сәбәбе бар, чөнки без Хилмия авылы хакындагы мәгълүматның иң элек үз милләттәшләребезгә барып ирешүен телибез.

Хилмия - Төркиянең Кара диңгез яры буендагы Самсун өлкәсенә караган Хавза районындагы кечкенә генә бер авыл. Без Хилмия авылының барлыгын очраклы рәвештә атаклы спортчы Бакия ханым Дуранның үзе турында язган китабыннан укып белгән идек. 2019 елның көзендә безгә шул авылга барырга һәм анда яшәүче татарлар белән күрешергә насыйп булды. Бу сәяхәтне оештыруда Самсун университеты доценты Сәйфуллаһ Гөл әфәнденең ярдәме зур булды, ул безне үз машинасында Хилмиягә кадәр алып килеп, авылның мохтары Нажи һәм аның бертуган кардәше Рәсим әфәнделәр белән күрештерде. Баксаң, Нажи һәм Рәсим әфәнделәр Бакия ханымның бертуган абыйлары булып чыкты һәм, сөйләшкәндә, алар зур горурлык белән сеңелләрен телгә алдылар. Сәяхәттән кайткач, бүгенге көндә Истанбулда яшәүче Бакия ханымның (1959) үзе белән элемтәгә кердек һәм аның турында “Мәдәни җомга” газетасында язып та чыктык (кара: Сибгатуллина, 2020). Ультрамарафон кебек авыр спорт төрен сайлаган һәм төрле ярышларда Төркия данын яклаган Бакия Дуран һаман

янып яши: физик культурага яшьләрне тарту өчен лагерьлар оештыра, халык алдында чыгышлар ясый, җитди рәвештә күнегүләр ясап, башкаларга үрнәк күрсәтә. Ни өчен аның марафончы булып китүен Хилмия авылын күргәч, тагын да яхшырак аңладык: таулы-чокырлы җиргә урнашкан авылның бер очыннан икенче очына барып кайтыр өчен шактый көч һәм вакыт кирәк. Юк, авылның территориясе зур түгел, ләкин инеш буеннан авыл башына чыгар өчен, текә генә тау башына күтәрелергә кирәк: ул тауны көнгә бер-ике тапкыр гына менеп төшсәң дә инде яхшы гына спорт күнегүе ясаган булып чыгасың. Балачагы шушы авылда үткән, игенчелек белән шөгыльләнеп яшәгән әти-әниләренә ярдәм итеп үскән Бакия, Наҗи, Рәсимнәр мондый авырлыкларга ияләшкән кешеләр инде. Тугыз балалы гаиләнең алтынчысы булган Бакия кечкенә вакытыннан ук эш сөеп үсә: тау битләрендә көтү көтә, бакча казый, яшелчә сулый, басуда урак ура, гаиләнең бөтен авыр хезмәтендә ир-атлар белән бертигез катнаша. “Кыюлык япа-ялгыз: бер ультрамарафончының хикәясе” (Duran, 2012) исемле китабында Бакия ханым үзенең спорт тормышын гына түгел, Хилмия авылының тарихын да шактый тулы һәм тәэсирле итеп бәян итә. Бабаларының Кара диңгез буйларына бәхет эзләп килеп тә, аны таба алмыйча йөреп аптырагач, кәрваннары белән тупланып, кире туган якларына кайтырга җыенганда, бер госманлы чиновнигының аларны кызганып, дәүләт казнасында булган таулы-ташлы, чокырлы-чакырлы бер урынны аерып бирүе һәм татарларның шунда торып калуы, ияләшелмәгән һәм уңайсыз шартларда өй салып, авыл корырга тырышуларын бөртекләп яза Бакия ханым.

Хилмия авылы тарихын барлаучы, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыючы тагын бер милләттәшебез бар: шушы авылда туып-үскән Әхмәт Шаһин әфәнде. Әбиләре янында кечкенәдән татарча сөйләшеп үскән Әхмәт әфәнде өлкән кешеләрдән ишеткән күп кенә җырларны отып калган һәм язып та алган. Хилмия авылына Татарстаннан беренчеләрдән булып килгән журналист Минназыйм Сәфәров Әхмәт әфәнде белән таң атканчы сөйләшеп утырулары хакында “Ватаным Татарстан” гәҗитендә бик матур итеп язып чыккан иде (Сәфәров, 2006). Әхмәт әфәнде Хилмиягә сәяхәтебездә безнең дә яныбызда булды, аннары үз өендә Хавзада кунак итте. Тормыш иптәше, тыйнак кына төрек кызы Гөл ханым, татар ашларын бик оста пешерә икән, безне табын әзерләп каршы алды, бәлешләр белән сыйлап кунак итте. Безнең белән күрешергә Әхмәт әфәнденең этисе Сәгадәтдин абый һәм әнисе Нәфия апа Шаһиннәр, дәү абыйсы Әмир Хөсәен һәм дәү апасы Хәйрия Дәмирҗаннар да килгән иде. Рәхәтләнеп татарча сөйләшеп-көлешеп утырдык, җырлашып-моңаешып та алдык.

**Авыл тарихы хакында**

Казан татарлары Самсун тарафларына XIX гасыр азагында Уфа губернасы Эстәрлетамак өязенең (хәзерге Башкортостан Республикасы Авыргазы районы) Курманай, Толбазы, Солтанморат, Исмәгыйль һәм башка якын-тирә авылларыннан килеп урнашканнар. Бу хакта Госманлы

архивы документларында да беркадәр мәгълүмат бар (Osmanlı Arşiv Belegelerinde Kazan, 2005:137-139). Бакия ханым яше туксаннардан узган Биби әбидән бала чагында ишеткәннәрен матур итеп китап битләрендә тасвирлап яза. Әбинең хикәясе 1860 нчы елларга, Курманай авылында оештырылган каз өмәләренә, кышның зәмһәрир суыкларына, күзен җитешкән эре бәрәңге басуларына барып тоташа, боларның берсен дә үз күзе белән күрмәсә дә, автор, хыял көчен дә кушып, мавыктыргыч итеп сурәтли. Ләкин язма гел хыял-фантазиягә генә корылмаган, авыл тарихын язганда Бакия ханымның ерак бабасы Габделхәким әфәнденең көндәлек-истәлек язмалары төп чыганак булып тора: татар телендәге истәлекләрнең копиясе Бакия ханымда, госманлыча язылганы Габделхәким әфәнденең апасының оныкларыннан берсе булган Хәйреттин Ялчында саклана икән.

Курманай авылында Габделхәким әфәнде он тегермәне тоткан, хуҗалыгында һәм иркен басуларында йөз иллеләп кеше хезмәт иткән. Госманлы дәүләтенә күченү фикере байга һәм авылдашларына кайчан һәм ни сәбәпле килүе билгеле түгел, чыганакларда һәм истәлекләрдә төгәл генә әйтелми, гомумиләштерелеп, Русиядә барган милли сәясәт, рус булмаган халыкларга ясалган басым аркасында дип кенә күрсәтелә. Халкыбыз арасында ул чорда бер шаукым булган солтан-хәлифә дәүләтенә һиҗрәт итү агымына иярүме, төрекләрдән килгән котыртучылар нәтиҗәсендәме, яки төбәктәге авыр империаль сәясәтме, билгесез, ни генә булмасын, соңыннан гомер буена үкендерәчәк күченү фикеренә авылдагы алтмыш гаилә кушылган икән, димәк, туган илне, торган йорт-җирне ташлап китәргә этәрүче сәбәпләр гаять җитди булган дигән сүз. Бакия ханым, госманлы хөкүмәтенең Кырымнан, Казаннан килгән төрки мөһаҗирләрне елда ике уңыш бирә торган туфраклардан биләмәләр, йорт-кура салу өчен бүрәнә-такталар белән тәэмин итә икән дигән халык арасында таралган сүзләрнең дә тәэсире көчле булуын искәртеп уза (Duran,2012:17).

Габделхәкимнең ике хатынынннан (беренчесеннән ике улы, бер кызы туа, ул хатыны вафат иткәч, икенчесен ала, аннан да өч улы була) туган балаларыннан бары тик иң олы улы Габдрахман гына һиҗрәткә кушылмый кала. Акчага әйләндерергә мөмкин бар нәрсә, амбарларда булган мал-икмәк сатылып бетә. Уфа, Бөгелмә, Казан маршруты белән Иделгә җиткән мөһаҗирләр, коры җирдән Кара диңгез буена килә, аннан исә Батумига таба юнәләләр. Юлда рус гаскәрләре туктатып, кая баруларын сораганда, эш эзләп йөрибез, диләр, көймәдәге әйберләрне тикшерә башлагач, көймә хуҗасы ришвәт бирергә мәҗбүр була, рус солдатлар аларның кайбер кыйммәтле нәрсәләрен алып калганга да, юлчылар бер сүз дәшә алмыйлар. Өйдән чыкканга бер атна дигәндә, Батумига барып җиткәч, бераз ял итәргә мөмкинлек туа, кунакханә хуҗасы Лаз Хөршид аларга Төркия чиген чыкканда русларның көчле контроле булуын, шуңа күрә әйберләрен үз яннарында алмаска киңәш итә, соңыннан үзенең ул әйберләрне Ризә шәһәренә җибәрәчәген вәгъдә итә. Ул дигәнчә эшлиләр, һәм төн

караңгылыгында алдан хәзерләнгән көймәгә утырып, Кара диңгезгә чыгалар. Ләкин бик тиз арада аларны рус гаскәре күреп ала һәм ут ача: 130 кешедән 19 ы һәлак була. Көймә хуҗасы мәетләрне суга атарга кушса да, халык риза булмый. 1899 елның 5 апрелендә Ризә шәһәренә килеп җитәләр һәм үлгән туганнарын тиешенчә җирлиләр. Калдырып киткән әйберләрен өч ай буе көтсәләр дә, Лаз Хөршид аларны җибәрми, шунлыктан кулларында ни җитәрлек кием-салым, ни табак-савыт берни булмый, бары тик самавырларыннан гына аерылмыйлар...

Госманлы хөкүмәтенең мөһаҗирләргә Самсунда җир бүлеп бирүен ишеткәч, татарлар да шул юнәлештә китәләр. Аларга яшәр өчен Чәршәмбе дигән урын күрсәтелә, ләкин ул урыннар сазлык җир булып чыга, безнең халык ул климатка ияләшә алмый, өч ай дигәндә малярия чире белән авыручылар күбәя, хәтта үлүчеләр дә була. Аптырагач, башка җиргә күчерергә сорыйлар. Бу тапкырында Малатья ягына җибәрәләр, анда да алты айдан артык кала алмыйлар: коры, ташлы-комлы урында иген игү түгел, иркенләп йөреп тә булмаганын, үзләре телгәнчә тормыш кора алмаячакларын аңлыйлар. Монда аларга башка җирләрдән, мәсәлән, Әби (Сарабиккол) авылыннан һиҗрәт итүчеләр дә кушылуы билгеле. Малатьядан Диярбакырга китәләр, ул якларда төрекләрдән күбрәк көртләр яшәгәнгә, телләрен белмәгәч, җирле халык белән аңлаша-аралаша алмыйлар. Беркайда да үзләренә урын таба алмаган мөһаҗирләр инде туган якларга кире кайтырга дигән фикергә киләләр. Ул арада Хавза дигән исем исләренә төшә, Төркиягә китүчеләрдән бу урынның Идел буйларына охшашлыгы турында ишеткәннәре була аларның, сынап карамакчы булып Амасйа провинциясе башлыгына хат язалар (ул вакытта әле Хавза районы Самсунга кермәгән була). Госманлы дәүләтенең рәсми документларында күренгәнчә, “Казанлы мөһаҗирләрнең” 1899 елда Хавзага килүе билгеле, барлыгы 16 гаилә булып, саннары 111 кешедән гыйбарәт (Osmanlı Arşiv Belegelerinde Kazan, 2005:138). Чыганакларда Даниш бәй исемле төрек чиновнигының аларга яшәр өчен дәүләт казнасыннан ике мең сутый җир һәм өй салырга агач материаллар бүлеп бирүе турында телгә алына. Шушы яхшы мөнәсәбәттән соң татарлар кире кайту фикереннән баш тарталар. Башта аларның авыллары хәзерге Хилмия урынында булмый, алар Хавзага якынрак булган хәзерге Кошйувасы, Шыршыр Эшмә исемле авыллар тирәсендә урнашалар, ләкин андагы черки-чебен оясына чыдый алмыйлар, җитмәсә, бер дә җил исми торган урын булганга, иккән игеннәрен сугара алмый интегәләр, шуңа күрә тагын бераз югарырак, ләкин таулы-ташлы җиргә күченергә мәҗбүр булалар. Яңадан өй-ихата кору, каткан җирне эшкәртү, су табу мәшәкате... XX йөз башына әкренләп Хилмия авылы формалашып җитә. Авылның исеме дә рәсми рәвештә Хилмия дип садразам (баш вәзир) тарафыннан раслана. Гадәттә, мөһаҗирләр салган авыл яки мәхәлләләргә солтанның яки вәзирләрнең исемнәре бирелә: Хәмидия, Газизия, Госмания кебек, бу очракта да авылның исеме күренекле дәүләт эшлеклесе Хөсәен Хилми-паша (1855-1922) белән бәйле булырга мөмкин.

1900 елгы документларда авылда 23 гаилә яшәгәнлеге күренә (Osmanlı Arşiv Belegelerinde Kazan, 2005:146). Бакия ханымның бабаларыннан Габделхәким һәм уллары Хаҗигали, Хаҗимөхәммәд, Мөхәммәдхәким һәм Мәүлет тә шунда калалар.

Мөһаҗирләр озак вакытлар туган яктан аерылу хәсрәте чигәләр, сагынып елап, кайберләренең күзләре сукырая, күпләр иртә картаялар. Рәсәйдәге сугышлардан, ачлыктан качып килгәннәрне Төркиядә дә шул ук хәлләр көтеп торган икән: Госманлы ватандашлыгына күчү белән авылның ир-атларын гаскәргә алалар, татарлар Балкандагы сугышларда, Беренче бөтендөнья сугышында, аннан соң милли-азатлык көрәшендә төрекләр, көртләр, чәркәсләр һәм башка милләт вәкилләре белән бер сафта сугышалар. Бакиянең үз бабасы Хаҗимөхәммәт Хәким дә бер фронттан икенчесенә җибәрелә, гомеренең 14 елын сугышта уздыра. Бары тик хатын-кызлар, бала-чага һәм картлар гына калган, мәркәздән ерак Хилмия авылында бәла-каза бер дә туктап тормый: әле юлбасарлар, сугыштан качып йөрүчеләр килеп куркыта, әле йогышлы кызамык авыруы таралып, балаларны аямый. Сугыштан соңгы елларда корылык һәм ачлык бик күпләрне аяктан ега, мәктәбе, юлы һәм җитәрлек иген басулары булмаган бу авылдан мөмкинлеге булганнар китә башлый, бер вакытлар хуҗалык саны алтмышка җиткән авылда (Рәсәйдәге большевик золымыннан качып килүче кайбер татарлар да бу авылга килеп урнаша) нибары биш-алты гаилә торып кала. Бакиянең әтисе Кязым шул авыр шартларда 1921 елда дөньяга килә, әнисе сугыш елларында фронтка корал ташып йөргәнгә, аны үзеннән ун яшькә олы апасы Фатыйма карый. 1925-1928 еллардагы Кара диңгез буендагы озакка сузылган коточкыч корылык татарларны тагын бер кат сыный. 1943 елда Самсунның Ладик районында булган 7,6 дәрәҗәдәге җир тетрәү аркасында ул төбәктә өч меңгә якын кеше үлә, мөһаҗирләрнең дә биналары зарар күрә.

Хилмия авылы район үзәге булган Хавзадан 15 чакрым ераклыкта. Авыл халкы кышын шунда күчә, чөнки авылга газ кермәгән, кышларын бик суык, ягарга ягулык юк. Авылның җир эшкәртү, яшелчә яки җиләк-җимеш үстерү, бакчачылык яки игенчелек белән шөгыльләнү өчен уңайсыз булуы, яшьләрнең эш табылмау аркасында район үзәгенә яки шәһәрләргә күченүе, шунлыктан халык санының да көннән-көн кимүе бик аңлашыла. Ләкин авыл ташландык түгел, Бакия ханымның берәр-берәр утырткан Амасйа сортлы алма, груша агачлары без килгәндә дә җимешләрен биреп утыра иде. Абыйлары авылны ташламый, Наҗи әфәнде, староста/мохтар буларак, мондагы йорт-җирләрне карап-саклап торса, Рәсим әфәнде исә помидор үстерү буенча остарып киткән. Авыл туфрагында үстергән помидорлардан алган уңышны тракторларга төяп базарда сата икән, безгә дә үзе җитештергән сорт орлыкларыннан өлеш чыгарды ул.

“Хәзер Хилмия авылы үзенә күрә бер символ гына булып калып бара инде. Кыш көне авылда өч кенә гаилә яши. Калганнары я Хавзада, я

Самсунда, я башка җирләрдә кышлый. Үзара хәбәрләшеп торабыз анысы: туйлар булганда, яки берәребез вафат булганда, бергә җыелабыз, - ди Әхмәт әфәнде Шаһин. Ул социаль челтәрдә авылга багышланган бер сәхифә (www.hilmiye.com) ачып җибәргән һәм якташлар, авылдашлар белән интернет аша якын элемтәдә тора, әбиләреннән язып алган җыр-такмаклар белән дә шунда уртаклаша. Әхмәт Шаһин 2007 елда Татарстан һәм Башкортостанга сәфәр кылып, бабаларының туган якларында булып килгән иде, мөмкинлек булса, тагын кайтыр идем, дип җан атып тора.

Авылдан чыкканнарның барысы да татарча яхшы сөйләшә дип әйтеп булмый, мәсәлән, Самсунда безгә Бакия ханымның икетуганы Фикри абый белән күрешеп сөйләшергә насыйп булды, гаять милли җанлы берсе булуга карамастан, ана телен бик аз белә, чөнки авылдан иртә чыгып киткән һәм башка тирәләрдә татарча сөйләшергә туры килмәгәнлектән, балачакта ишеткән татар сүзләре дә әкренләп хәтереннән җуелган.

Хилмия-Хавза арасында кунак булып йөргәндә, җирле халык арасында үзенә күрә бер самавыр культы бар кебек тоелды безгә: һиҗрәт вакытында да иң кадерле нәрсә самавыр булганын, хәтта алтын йөгертелгән бер самавырны үзләре белән алган булганнар да, рус гаскәрләре аны алып калганнар дигән бер легендага охшаш хәтирә дә йөри мондагы татарлар арасында. Безнең белән бергә табында утырган әби-апалар да “Самавыр куйдым кайнарга Казаннардан килгән байларга” дип җырлап куйдылар. Болай самавырга мәхәббәтнең гомумән бу төбәккә хас булуын Хавзада урнашкан бар Төркияне самавыр белән тәэмин итүче “Сөзәнләр” фирмасына баргач тагын да ачыграк аңладык. Төрле материалдан әллә ничә төрле формаларда җитештерелә торган самавырларны ясаучы осталар белән таныштык, цехка кереп эш процессын да карап тордык. Фирма хуҗалары безне туйганчы самавыр чәе белән сыйлады, шул табында укылган бер әсәр игътибарыбызны аеруча җәлеп итте, исеме русчадан килгән дип уйлаган *самовар* ның төрки-мөселман дөньясында никадәр әһәмиятле урын тотуын белдерүче бу “Самавыр касыйдәсен” монда да тәрҗемә итеп бирүне кирәк таптык:

**Semaver Kasidesi**
Semaveri koydum düze,
Gelin, kardeşler, hep bize.
Hak yetişsin imdadımıza,
Yan, semaver, dön, semaver.
Limon, şeker, çay, semaver.
Semaverin suyu çiçek.
Gelin, kardeşler, çay içek.
Çaysız meclisi nidek,
Yan, semaver, dön, semaver.
Sana gurban can semaver.

Semaverin musluğu var,
Çoban gibi ıslığı var,
Dervişlerin dostluğu var,
Çay içelim, çay içelim,
Nefsi havadan geçelim.
Semaveri alıştıralım,
Maşa ile karıştıralım,
Küskünleri barıştıralım,
Yan, semaver, dön, semaver.
Limon, şeker, çay, semaver.
Semaverin hocası var,
Kafkaslarda nicesi var.
Buhara'da yücesi var.
Yan, semaver, dön, semaver,
Atamızdansın yadigar.

**Самавыр касыйдәсе**
Самавыр куйдым тигезгә (тигез җиргә),
Килегез, кардәшләр, безгә.
Хак тәгалә ярдәм итсен безгә,
Ян, самавыр, кайна, самавыр,
Лимон, шикәр, чәй, самавыр.

Самавырның суы чәчәкле,
Килегез, кардәшләр, чәй эчик,
Чәйсез мәҗлес һич булмас,
Ян, самавыр, кайна, самавыр,
Җаныбыз фида сиңа, самавыр.

Самавырның борыны бар,
Көтүченекедәй сыбызгысы бар,
Дәрвишләрнең дуслыгы бар,
Чәй эчәек, чәй эчәек,
Нәфесебезне җиңәек.

Самавырны тагын кабызыйк,
Күмерләрен бераз болгатыйк,
Үпкәләгәннәрне килештерик,
Ян, самавыр, кайна, самавыр,
Лимон, шикәр, чәй, самавыр.

Самавырның хуҗасы бар,
Кавказда да андыйлар күп,
Бохарада исә -  иң бөеге.

Ян, самавыр, кайна, самавыр,
Аталардан калган ядкаребез.

**Халык җырлары үрнәкләре**

Түбәндә китерелгән такмак һәм җырларны без Әхмәт Шаһиннән тыңладык. Ул исә 1980 нче еллардан башлап, әлеге әсәрләрне язып алу белән шөгыльләнгән. Аның информантларның да исемнәрен монда искә алуны кирәк саныйбыз.

1. **Мәрьям Шаһин** (1910-1992) - Әхмәт әфәнденең әтисе ягыннан әбисе. Башкортостанның Авыргазы районы Толбазы Солтанморат авылыннан чыккан Җәмил абзый белән Миннеямал апаның кызы.

Яңгыр ява шыбыр-шыбыр өй башында калайга,
Йомышың булса, әйтеп җибәр урамдагы малайга.

Алтын алка колакта ла, ялтырыйдыр яңакта,
Үзе анда бик еракта, дәрте миндә йөрәктә.

Әйттер, җаный, әйттер, җаный, әйттергәннәрең калыр.
Ашап-эчеп, уйныйк-көлик, сагынып сөйләргә калыр.

Утыр, утыр урындыкка, аякларың талмасын,
Калса калсын минем хәтер, синең хәтер калмасын.

Аппак идем, ак каз идем, сусыз җирдә кагындым,
Ак чырайлы бала идем, хәсрәт күрдем, саргайдым.

Әнкәй, балта бирсәнә, тал ботагын бутаем,
Яшьли күргән җаныемны ничек итеп онытаем.

Әйдә барыйк, әйдә кайтыйк, чана шуган эз белән,
Үпкәләмә, җаныкаем, уйнап әйткән сүз белән.

Хатлар яздым утырып, ак кәгазьгә тутырып,
Хат җибәрдем, җылап калдым, язган җирдә утырып.

Тәрәзәдән карашыйк, алтын йөзек алышыйк,
Ахирәткә калдырмасын, дөньялыкта кавышыйк.

Алма бирдем, алдың бит, ак яулыкка салдың бит.
Җанкай диеп йөргән булдың, җанкай, миннән калдың бит.

**2.Нурия Дәмирҗан** (1910 тирәсе-1996)- Әхмәт Шаһинның әнисе ягыннан әбисе. Чыгышы белән Толбазы яки Курманай авылыннан. Әтисенең исеме Нәкый, әнисенеке Хәлимә.

Мендем таулар башынай, бастым гәүрән ташынай,
Аккош очып йитмәс йирләргә алып китте машинай.

Аккош очар, җонкайларын кояр, аның җонкайларын кем җыяр,
Ят йирләрдә вафат итсәк, җиназәләр укып, кем куяр.

Күк күгәрчен күрилдә лә, мәчет манарасында,
Хәсрәт-нәстә күрмәгән идем дус-дошман арасында.

Үтәсең ник, гомерләрем, картайтып ла әрәм итәсең,
Картайтканга әй үкенмим, үтереп әрәм итәсең.

Күк күгәрчен күрилдә лә, чыгарып бодай сибегез,
Минем җанкай бик җыласа, кереп үгет бирегез.

Сары-сары сандугачлар саздан сары камыш китерер,
Адәмнәрдән адәм артмай, күп адәмне хәсрәт бетерер.

**3.Зәйтүнә Баскан** (?-2007) – әти-әнисе Казан шәһәреннән. Революциягә кадәр әтисе бай мануфактурачы булып, хәйрия эшләре белән танылган. Сталин чорында гаиләсе белән Азәрбәйҗанга китеп, өч ел тимерчелек белән көн күргән, 1935 елда Иран аркылы Төркиягә качарга мәҗбүр булган. Самсунда татарлар яшәвен ишеткәч, шунда калырга уйлаган.

Самавыр куйсаң кайнарга, каен булсын күмерең
Безгә кунак килгән өчен, озын булсын гомерең.
Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)

Күк күгәрчен күкләрдән, шул, төшкән бодай чүпләргә,
Инде ни хәлләр итәргә, вакыт килде китәргә.
Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)

Безнең илләр кайсы якта, алмас идем күземне,
Очып барган кош артыннан әйтер идем сүземне.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Прахуд килә,  прахуд килә,  диңгез өстен туздырып.
Елый-елый гомерем бетте, яшь гомерләр уздырып.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Аклы ситсы күлмәгеңне кигәнеңне күрмәдем,
Бик сагындым, бик саргайдым, әле дә ярый үлмәдем.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Самавыр куйсаң кайнарга, каен булсын күмерең
Безне кунак иткән өчен, озын булсын гомерең.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Сары-сары сап-сары ла, сары чәчәк саплары,
Иртә көтәм, кич тә көтәм, килми сәлам хатлары.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Хатлар яздым утырып ла, ак кәгазгә тутырып,
Хатны салдым елап калдым, язган йирдә утырып.

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)
Тәрәзә пыяласына исмең куяласыңмы?
Төнлә төшләрендә күреп, җылап уянасыңмы?

Сандугач-күгәрчен, хәсрәт чигәм, күрәмсең (2 тапкыр)

**Йомгак**

Төркиядә Казан татар авыллары чагыштырмача күп түгел, иң эреләре булып Госмания, Бөгредәлик, Караһөек, Әфәнде Көпрүсү авыллары санала, Искешәһәрдәге татар җәмгыяте шактый зур һәм актив хәрәкәт итә. Әмма глобальләшү чоры дип аталган бу заманда Төркиядә яшәүче татарлар да үз телләрен һәм культураларын югалту куркынычы алдында торалар. Ни кызганыч, Самсун татарлары да әкренләп төрекләшә, кечкенә генә Хилмия авылы да үз йөзен югалта бара. Әхмәт әфәнде Шаһин Төркиядә безгә бик билгеле булмаган башка кечкенә татар авыллары булуын да әйтте. Мәсәлән, Йозгат өлкәсендәге Соргун районындагы Чампынар авылы шундыйлардан икән. Үзе барып күргән бу авыл тарихы турында сөйләгәндә, Әхмәт әфәнде аның Хилмия авылы белән бер тирәдә, 1898 елда нигезләнүен әйтте, бу урынга татарлар хәзерге Сарман районы Ләшәү Тамак, Азнакай районы Кәкре Елга авылларыннан килгәннәр дигән фикердә тора. Бүгенге көндә Чампынар авылында утызлап гаилә яши, өлкән яштәге татарлар туган телендә сөйләшә алсалар да, яшь буын инде “аңлый, ләкин сөйләшми” икән.

Төркиядәге татар диаспорасын барлау һәм өйрәнү эше системалы һәм фәнни нигезгә салынуны сорый торган өлкә, шуңа күрә татар һәм төрек галимнәре, көчләрен берләштереп, бу темага аерым игътибар итсеннәр иде дигән теләктә калабыз.

**Чыганаклар**

Duran Bakiye. *Cesaret Yalnızdır. Bir Ultra Maratoncunun Hikayesi*. İstanbul, 2015.

*Osmanlı Arşiv Belegelerinde Kazan*. Ankara, 2005.

Сәфәров Минназыйм. 130 елдан соң инкыйраз?//*Ватаным Татарстан*, 2006. 11 август.

Сибгатуллина Әлфинә. Ультрамарафончы татар кызы// *Мәдәни җомга*, 2020. 4 февраль.

## МАТЕРИАЛЫ К ИСТОРИИ И ФОЛЬКЛОРУ СЕЛА ХИЛЬМИЯ

### Аннотация

Населенных пунктов в Турции, где компактно проживают казанские татары, относительно немного. Наиболее крупными такими селениями являются Османия, Бёгрюделик, Карахоек, Эфенди Кёпрюсю и др. Большая татарская община существует в городе Эскишехир. Небольшое татарское село Хильмия находится в районе Хавза, который в настоящее время входит в состав провинции черноморского города Самсун. Татары переселились туда в 1899-1901 годах из деревень Курманаево, Исмагилево, Толбазы, Султанмурат, бывшего Стерлитамакского уезда Уфимской губернии (современный Аургазинский район Республики Башкортостан). Отдельные материалы относительно истории переселения сохранились в османских архивах и воспоминаниях самих жителей села, однако конкретная причина переселения нигде не указывается. Надо полагать, что были весьма значимые экономические и идеологические причины, чтобы оставить родные места и выехать в незнакомую страну. Дорога в Османскую империю была трудной, по пути они дали немало материальных и людских потерь. Уроженка села Бакия Дуран на основании преданий своих родственников пишет, что возглавлял группу переселенцев его прадед Габделхаким. Они прибыли через Батуми в г. Ризе, оттуда их отправили в г. Чаршамба, где им было указано место для проживания. Однако из-за болотистой почвы среди них развилась эпидемия малярии, и они вынуждены были запросить другой участок. После этого мухаджирам были представлены земли в провинциях Малатья и Диярбакыр, но они и там не смогли найти удобное место для поселения, и в итоге захотели вернуться обратно на родину. В последний раз было принято решение попытать счастье на территории Хавзы, которая тогда входила в состав провинции Амасья. Государство им снова выделило участок и древесину для строительства домов. Первичное место расположения села было чуть подальше, лишь спустя некоторое время татары основательно устроились на нынешней территории села Хильмия. И здесь жизнь налаживалась очень сложно, привыкали татары к чужбине долго, тоска по родине и близким людям, сожаление о предпринятой

иммиграции, все это проникновенно отразились в их фольклоре. Житейские трудности усилились с мобилизацией мужчин села в армию и их участием в войнах, которые следовали друг за другом. Отсутствие школы и газификации, удаленность от центра, безработица и другие обстоятельства привели к уменьшению населения села, в настоящее время в Хильмии проживает всего три семьи. Осенью 2019 года нам удалось посетить село Хильмия и записать некоторые народные песни и воспоминания у старожилов. В деле изучения истории села вносят свой вклад уроженцы села Ахмет Шахин и известная спортсменка Бакия Дуран.

К сожалению, казанским татарам, проживающим на территории Республики Турция, грозит постепенная ассимиляция и потеря родного языка. К тому же здесь существуют такие малые населенные пункты с татарским населением, которые абсолютно неизвестны в Республике Татарстан. Об одном из таких сел под названием Чампынар сообщил нам Ахмет Шахин. Все это говорит о том, что сегодня существует острая необходимость всестороннего научного изучения истории, культуры и фольклора татарской диаспоры в Турции. Для этого нужна совместная целенаправленная работа российских и турецких тюркологов и историков.

**Ключевые слова:** Казанские татары, мухаджирство, Черное море, Хильмия, татарское устное народное творчество.